**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Ульяновка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**№ 141** **«27» декабрь 2024 ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль
районы Ульяновка авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2019 елның 18 февралендәге №108 карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 18 февралендәге №108 карарына (Советның 13.06.2019 №114, 30.09.2021 №43; 23.08.2024 № 126 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

- 2 абзацның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашканнары, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата».

- 3 абзацның 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе С.З. Шәмсетдинов